Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының
Шәле авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шәле авыл җирлегенең Шәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

12 ноябрь, 2020 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлегенең Шәле торак пункты гражданнарының 2020 елның 12 ноябрендәге җыены беркетмәсе нигезендә түбәндәгеләр ачыкланды:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм гражданнар җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 2206 (ике мең ике йөз алты).

- халык җыены эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны 1163 (бер мең бер йөз алтмыш өч).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 1125 (бер мең бер йөз егерме биш).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 38 (утыз сигез).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2021 елда Шәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, Чернобыль АЭСдәге аварияне бетерүдә катнашучыларны, 1 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрне, сугыш һәм хәрби хәрәкәтләрендә катнашучыларны, Чернобыль АЭСдәге аварияне бетерүдә катнашучыларны, ялгыз аналарны, 80 яшькә җиткән гражданнарны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Шәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Шәле авыл җирлеге башлыгы И.Р. Әхмәтҗанов